ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унбишенче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унбишенче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасына билгеләп кую турында.
2. Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларының вәкаләтләрен туктату турында.
3. Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларын сайлау турында.
4. «Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен дифференциацияләнгән салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 112-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
5. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 113-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
6. «2021 елга Татарстан Республикасында хезмәт базары үзенчәлекләрен чагылдыра торган региональ коэффициентны билгеләү турында» 115-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
7. «Пенсиягә федераль социаль өстәмә күләмен билгеләү өчен Татарстан Республикасында 2021 елга пенсионерның яшәү минимумы күләмен билгеләү турында» 114-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
8. Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе урынбасарын билгеләп кую турында.

9. «2021 елга Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 116-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

10. «2021 елга Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 117-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

11. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 110-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

12. «Татарстан Республикасы Җир кодексының 9 һәм 25 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 109-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

13. «Татарстан Республикасы закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 111-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

14. Кулланучылар хокукларын яклау һәм кешенең имин тормышы өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе мәгълүматы.

15. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 284 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Хакасия Республикасы Югары Советының закон чыгару инициативасы хакында.

16. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты составындагы үзгәреш турында.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2020 елның 18 сентябре
№ 596-VI ДС